**Республика Татарстан**
**Палата имущественных и земельных отношений Заинского муниципального района**

ул.Автозаводская, д.1А, г.Заинск,
Республика Татарстан, 423520
тел.2-80-31, 2-80-34
факс: 8(85558)2-80-33

**Татарстан Республикасы**
**Зәй муниципаль районының милек һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы**

Автозавод урамы, 1А йорт,
Зәй шәһәре Татарстан
Республикасы, 423520
тел.2-80-31, 2-80-34
факс: 8(85558)2-80-33

**РАСПОРЯЖЕНИЕ** **БОЕРЫК**

«05» 08 2024ел №666П

**«Зәй муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасының 2021 елның 13 августындагы 617п номерлы боерыгы белән расланган җир кишәрлеген арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында»**

"Дәүләт һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүне оештыру турында" 2010 елның 27 июлендәге 210-ФЗ номерлы Федераль законны гамәлгә ашыру максатларында Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының «Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте Башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү хакында» 2010 елның 2 ноябрендәге 880 номерлы карарына, Татарстан Республикасы Зәй муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы, Зәй муниципаль районының Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасы турында нигезләмәгә таянып

**боерык бирә:**

1. Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасының 2021 елның 13 августындагы 617п номерлы боерыгы белән расланган, җир кишәрлеген арендага бирү буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең административ регламентына үзгәреш кертергә, аны кушымтага ярашлы рәвештә яңа редакциядә бәян итәргә.
2. Әлеге боерыкны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (prav.tatarstan.ru) һәм Зәй муниципаль районының рәсми сайтында бастырып чыгарырга.
3. Әлеге боерык рәсми рәвештә басылып чыкканнан соң үз көченә керә.

4. Әлеге Боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны Зәй муниципаль районы Мөлкәт һәм җир мөнәсәбәтләре Палатасының җир мөнәсәбәтләре бүлеге начальнигы Т.Н. Кузнецовка йөкләргә.

**Палата рәисе** **Р.Р. Шәйхиев**

Юрисконсульт